# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Тубылгы Тау авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 17 октябре №1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 16 нчы октябрьдә 12.00 сәгатьтә, 16 нчы октябрьдә 15.00 сәгатьтә, 16 нчы октябрьдә 17.00 сәгатендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәрбер гражданнан, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугыш ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 нче төркем инвалидлардан тыш 500 сум күләмендә салым җыярга һәм җыелган сумманы түбәндәге эшләргә тотуга ризамы:

- Яшьләр урамы, Дуслык урамы, Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- юлларны грейдлау (килешү буенча түләү)»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 446 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 282 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 281 кеше тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 1 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карарны: « Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәрбер гражданнан, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугыш ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 нче төркем инвалидлардан тыш 500 сум күләмендә салым җыярга һәм җыелган сумманы түбәндәге эшләргә тотуга ризамы:

- Яшьләр урамы, Дуслык урамы, Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- юлларны грейдлау (килешү буенча түләү)» - кабул итәргә.

3. Тубылгы Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмәгыйлев